ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КҮҖӘКӘ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423734, Күҗәкә авылы, Совет урамы.,
28 нче йорт. Тел.3-44-48

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУЗЯКИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423734, село Кузякино,
ул. Советская,дом 28, Тел. 3-44-48

Карар
17.06.2019

Карар
№14

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге башкарма комитетының 12.02.2013 ел 5 санлы « Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турындагы» карарына үзгәрешләр кертү турында

2017 елның 29 декабрендәге 479 санлы-ФЗ "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" , мөрәҗәгать итүче тарафыннан бердәм гариза бирү юлы белән, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү мөмкинлеген беркетү өлешендә, Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге Уставы белән, Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге башкарма комитетынын 12.02.2013 ел 5 санлы «Башкарма комитет тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турындагы” карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлегенең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

- 5) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәк, әлеге Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү буенча судка кадәр (судтан тыш) тәртибе."

1.2. 3.5 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3.5. Административ регламент бүлекчәсен әзерләү, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсә?үче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук әлеге Федераль законның 16

статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү тәртибенә карата судка кадәр (судтан тыш)".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында Күҗәкә авыл җирлеге хәбәрләре бүлегендә урнаштырырга.

3.Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Күҗәкә авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Н.Мусин